КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 июнь г.Казань № 517

Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәкләрендә комплекслы сорату аркылы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары күрсәтүне гамәлгә ашырмый торган дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясындагы 13 өлеш нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Кararга теркәлгән Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәкләрендә комплекслы сорату аркылы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары күрсәтүне гамәлгә ашырмый торган дәүләт хезмәтләре исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәкләрендә хезмәт күрсәтә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, шулай ук «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәкләре базасында комплекслы сорату аркылы дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру барышында Исемлеккә таянып эш итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 26 июнь, 517 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәкләрендә комплекслы сорату аркылы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары күрсәтүне гамәлгә ашырмый торган дәүләт хезмәтләре исемлеге**

| | |
|---|---|
| **Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы** | |
| 1. | Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат бирү |
| 2. | Гражданнарга яраклы эш, эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуга булышлык крсәтү |
| 3. | Татарстан Республикасында эшчәнлек өлкәсен (һөнәрне) сайлау, эшкә урнашу, һөнәри укыту узу һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарның һөнәри ориентациясен оештыру |
| 4. | Татарстан Республикасында түләүле җәмәгать эшләре үткәрүне оештыру |
| 5. | Татарстан Республикасында укудан ирекле вакытта 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә авырлыклары булган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемнәре булган һәм беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькәчә эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру |
| 6. | Эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә булышлык күрсәтү, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган, эш белән тәэмин итү органнары юлламасы буенча һөнәри уку үткән яки өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга алар юридик зат, шәхси эшмәкәрлек яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп |
| 7. | Татарстан Республикасында хезмәт базарында эшсез гражданнарның социаль адаптациясе |
| 8. | Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү |
| 9. | Татарстан Республикасы халыкны эш беләнтәэмин итү хезмәтләренең дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен эшсез гражданнарга күчеп килүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаиләләре әгъзаларына башка җирлеккә күченүдә булышлык күрсәтү |

| | |
|---|---|
| 10. | Эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү, башка җирлектә укытуны кертеп |
| **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе** | |
| 1. | Гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкны кабат бирү |
| 2. | Никахны дәүләт теркәвенә алу |
| 3. | Балигъ булу яшенә җитмәгән уртак балалары булмаган ир белән хатынның уртак ризалыгы белән никахны өзүне дәүләт теркәвенә алу |
| **Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы** | |
| 1. | Кара һәм төсле металл ломын әзерләү, эшкәртү һәм тормышка ашыру эшчәнлеген лицензияләү |
| **Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы** | |
| 1. | Урманнан файдалануны гамәлгә ашыручы гражданнардан, юридик затлардан урман декларацияләре һәм урманнан файдалану турында хисаплар каблу итү |
| 2. | Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен аукцион үткәрмичә арендага бирү |
| 3. | Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен аукцион нәтиҗәләре буенча арендага бирү |
| 4. | Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләрен төзү |
| 5. | Урманнар үзләштерү проектына дәүләт экспертизасы үткәрү |
| 6. | Урман кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү |
| 7. | Урман кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү |